ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 1 өлештә:
10 пунктта «һәм җибәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;
$13^{4}$ пунктта «1 – 4» саннарын «1 һәм 2» сүзләренә алмаштырырга;
$13^{7}$ пунктта «күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренә» сүзләрен «урыннар милекчеләренә» сүзләренә алмаштырырга;
$13^{8}$ пунктта «күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренә» сүзләрен «урыннар милекчеләренә» сүзләренә алмаштырырга;
$13^{10}$ пунктта «күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләренә» сүзләрен «урыннар милекчеләренә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 өлешнең 3 пунктында «үз исеменә махсус счет ачылган зат» сүзләрен «махсус счет хуҗасы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында «күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре» сүзләрен «урыннар милекчеләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяның $1^1$ өлешендә «күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләреннән» сүзләрен «урыннар милекчеләреннән» сүзләренә алмаштырырга;

4) 8 статьяның 1 өлешендә «электр энергиясе,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) $9^1$ статьяда «Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы» сүзләрен «торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

6) 10 статьяның 10 өлешендәге 5 пунктында «Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясының $3^1$ өлеше нигезендә йорт эчендәге газ белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау, файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазын ремонтлау яисә алмаштыру» сүзләрен «йорт эчендәге газ белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау, лифтларны ремонтлау, алмаштыру, яңарту, лифт шахталарын, машина һәм блок бүлмәләрен ремонтлау» сүзләренә алмаштырырга;

7) 11 статьяның 2 өлешендә «файдалану өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазын ремонтлау яисә алмаштыру» сүзләрен «лифтларны ремонтлау, алмаштыру, яңарту, лифт шахталарын, машина һәм блок бүлмәләрен ремонтлау» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 12-ТРЗ